

Икенче ел рәттән «Кече шәһәрләр һәм авылларнын мәдәни мозаикасы» Ботенроссия конкурсынын регионара этабы Темников шәһәрендә һәм районнын авылларында үтә. Якшәмбе конне «Россиянен кечкенә энжеләре» Регионара фестивале кысаларында Темник районы Тархан авылында татар халкынын милли йолаларынын берсе булган уныш бәйрәме - «Сомбелә» үтте. Алар бу бәйрәмне «Ипи коненә» багышлаганнар.

Бу юкка түгел, чонки бүгенге кондә халкыбызнын онытыла башлаган матур бәйрәмен янарту ул. «Сомбел» сүзенен килеп чыгышы белән безнен эрага кадәр Азиядә яшәгән һәм игенчелек белән шогыльләнгән борынгы шумерларнын мәдәниятенә барып тоташа. Алар телендә «шумбул», «сары башак» дигән мәгънәгә туры килә һәм «Сомбелә» – «башак» дигән сүз ул.

Сомбелә ае кон белән тоннен козге тигезләшкән чорына - 22 сентябрьгә туры килгән һәм бу конне Сомбелә бәйрәме




үткәрелгән. Бу бәйрәм асылда кон белән тоннен язгы тигезләшкән чорында - 21 мартта уздырылучы Нәүрүз бәйрәменен капма – каршы парын тәшкил иткән. Нәүрүз бәйрәме аграр хужалык елын, ягъни игенчелек циклын башлап җибәрсә, Сомбелә бәйрәме аны тәмамлап – йомгаклап куйган. Чонки бу вакытта инде урып – җыю эшләре һәм ужымга сорү тогәлләнә торган булган, ашлык кибән – эскертләргә куелган, сугылганы келәт – амбарларга тутырылган. Менә шундый козге муллык – туклык чорына туры килгәнгә күрә дә, халык Сомбелә бәйрәмен, аеруча мул сый – ризык әзерләп, күтәренке күнел белән үткәрелә торган булган: һәр ойдә бу конгә яна уныштан торле камыр ашлары әзерләнгән, тәмлүшкалар пешерелгән. Ял коне үткәрелгән бәйрәмдә дә шулай булды. Бәйрәмне райо



